КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 11 сентябрь г.Казань № 827

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 22 гыйнвар, 22 нче; 2005 ел, 30 май, 239 нчы; 2006 ел, 2 октябрь, 490 нчы; 2007 ел, 6 апрель, 123 нче; 2008 ел, 8 сентябрь, 640 нчы; 2010 ел, 29 ноябрь, 956 нчы; 2011 ел, 21 июнь, 496 нчы; 2011 ел, 6 декабрь, 1001 нче; 2012 ел, 13 апрель, 304 нче; 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 8 февраль, 80 нче; 2014 ел, 5 декабрь, 947 нче; 2015 ел, 15 апрель, 254 нче; 2015 ел, 1 декабрь, 911 нче; 2016 ел, 22 июнь, 425 нче; 2016 ел, 10 сентябрь, 625 нче; 2016 ел, 20 декабрь, 959 нчы; 2017 ел, 10 май, 268 нче; 2017 ел, 28 август, 604 нче; 2017 ел, 27 октябрь, 812 нче; 2017 ел, 1 ноябрь, 833 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 7 март, 163 нче; 2019 ел, 5 август, 644 нче; 2019 ел, 10 декабрь, 1131 нче; 2020 ел, 2 июнь, 461 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9.2 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмау турында»;

9.4 нче пунктның икенче абзацына татар текстында «документларны» сүзеннән соң «, бу Нигезләмәнең 9.1 нче пунктында күрсәтелгән гражданнарның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булу» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 14 февраль, 97 нче карары белән (Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинетының 2012 ел, 11 февраль, 105 нче; 2014 ел, 2 сентябрь, 635 нче; 2015 ел, 19 март, 165 нче; 2017 ел, 26 май, 307 нче; 2018 ел, 12 декабрь, 1117 нче; 2019 ел, 7 март, 163 нче; 2019 ел, 26 сентябрь, 877 нче; 2020 ел, 12 июнь, 485 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 нче пунктның 2.2.1 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2.1. Ведомствоара сораулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып электрон формада гражданны юллама алуга исәпкә кую турында карар кабул итү өчен кирәкле түбәндәге мәгълүматларны ала:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә вәкаләтле оешмалардан пенсия билгеләү турында;

вәкаләтле оешмалардан гариза бирүченең гаилә составы турында;

Россия Федерациясе Пенсия фондында, Федераль салым хезмәтендә булган керемнәр турында;

күчемсез мөлкәт булу турында;

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм техниканың башка төре булу турында;

торак урынны яшәү өчен яраксыз дип билгеләнгән тәртиптә тану турында;

индивидуаль шәхси счетның иминият номеры (СНИЛС) турында;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмау турында.

Шифаханә-курорт дәвалавына медицина күрсәткечләре булу турында мәгълүмат алмашу мәсьәләсе буенча ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек алып барганнан соң, шифаханә-курорт дәвалавына медицина күрсәткечләре булу турында белешмәләр ала.

Граждан үз инициативасы белән территориаль социаль яклау органына, гариза белән бергә, бу пунктның икенче – тугызынчы абзацларында күрсәтелгән мәгълүматлар бирелгән документларны тапшырырга хокуклы.»;

2.4 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гражданның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булу.»;

3.1 нче пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чират нигезендә шифаханә дәвалавы юнәлеше буенча юллама (юллама керү турында мәгълүмат) кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көн эчендә гражданга шифаханә дәвалавы юнәлеше буенча юллама керү һәм бу Тәртипнең 2.1 нче пунктында күрсәтелгән документларны (аларның гамәлдә булу вакыты чыккан очракта) эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көн эчендә яңартырга кирәклеге турында почта аша яки гражданның теләге белән гаризада күрсәтелгән ысулларның берсе (телефоннан, йә СМС-хәбәр җибәреп, йә электрон почта аша) ярдәмендә хәбәр итә;»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бу пунктның икенче абзацы нигезендә шифаханә дәвалавы юнәлеше буенча юллама (юллама керү турында мәгълүмат) керү турында мәгълүмат бирелгән граждан

тарафыннан яңартылган документлар һәм мәгълүматлар тапшырылган һәм территориаль орган тарафыннан алар алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көн эчендә юллама бирү яки аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карар турында гражданга почта аша яки гражданның теләге белән гаризада күрсәтелгән ысулларның берсе (телефоннан, йә СМС-хәбәр җибәреп, йә электрон почта аша) ярдәмендә хәбәр итә.»;

алтынчы абзацта «2.2.1 нче пунктындагы икенче – алтынчы абзацларында» сүзләрен «2.2 нче пунктындагы 2.2.1 нче пунктчасының икенче – тугызынчы абзацларында» сүзләренә алыштырырга;

3.5 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гражданның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булу.»;

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү турында» 2012 ел, 7 март, 188 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 29 май, 429 нчы; 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 828 нче; 2015 ел, 29 июль, 550 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 997 нче; 2017 ел, 13 июль, 494 нче; 2017 ел, 1 ноябрь, 833 нче; 2019 ел, 17 сентябрь, 839 нчы; 2020 ел, 2 июнь, 461 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган 18 яшькә кадәрге инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Айлык акчалата түләү бирү турында карар кабул итү өчен Үзәк бүлеге ведомствоара сораулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып электрон формада түбәндәге мәгълүматларны ала:

граждан хәле актларын теркәү органыннан бала тууны (уллыкка алуны) дәүләт теркәвенә алу турында;

вәкаләтле оешмалардан инвалид балага опека (попечительлек) билгеләү турында;

вәкаләтле оешмалардан инвалид баланы тәрбиягә бала алган гаиләгә тапшыру турында;

вәкаләтле оешмалардан гариза бирүченең даими яшәү урыны буенча аның белән бергә яши торган затлар турында;

Россия Федерациясе Пенсия фондыннан инвалид баланың үз-үзенә хезмәт күрсәтү сәләте чикләнүенең өченче дәрәҗәсе турында билгесе булган инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасыннан;

законлы вәкил тарафыннан эшкә сәләтсез гражданнарны карауны гамәлгә ашыручы затларга билгеләнгән компенсация түләвен алуны раслый торган;

халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт хезмәте органыннан эшсезлек буенча пособие (стипендия һәм башка түләүләр) алу һәм аның күләме турында;

Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан гамәлгә ашырыла торган пенсия һәм башка социаль түләүләр алу һәм аларның күләмнәре турында;

Федераль салым хезмәтеннән физик затларның алынган керемнәре турында;

социаль яклау органыннан социаль түләүләр алу һәм аларның күләмнәре турында;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмау турында.

Гариза бирүче яки аның тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән зат үз инициативасы белән Үзәк бүлегенә бу пунктта күрсәтелгән мәгълүматлар бирелгән документларны тапшырырга хокуклы.»;

11 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гариза бирүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булу.»;

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү турында» 2018 ел, 9 февраль, 67 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 25 июнь, 507 нче; 2019 ел, 22 август, 698 нче; 2020 ел, 26 февраль, 148 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү балалары тулысынча дәүләт тәэминатында булган гражданнарга, ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән йә ата-ана хокукы чикләнгән гражданнарга, шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булган гражданнарга билгеләнми.»;

7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Үзәк бүлеге ведомствоара сораулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып электрон формада бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү бирү турында карар кабул итү өчен кирәкле түбәндәге мәгълүматларны ала:

бала (балалар) тууны дәүләт теркәвенә алу турында – Татарстан Республикасы территориясендә бала (балалар) тууны дәүләт теркәвенә алган очракларда;

атасы (анасы) вафат булуны дәүләт теркәвенә алу турында – Татарстан Республикасы территориясендә үлем акты теркәлгән очракта;

опека (попечительлек) билгеләү турында;

ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү яки ата-ана хокукларын чикләү турында;

Татарстан Республикасы территориясендә авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда кимендә өч ел даими яшәү фактын (бу Нигезләмәнең 6 нчы пунктындагы бишенче абзацында күрсәтелгән очрактан тыш) раслый торган;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмау турында.

Гариза бирүче үз инициативасы белән Үзәк бүлегенә бу пунктта күрсәтелгән мәгълүматлар бирелгән документларны тапшырырга хокуклы.»;

9 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләүдән баш тарту өчен тапшырылган мәгълүматлар һәм (яки) документлар нигезендә ачыкланган аны алу хокукы булмау нигез булып тора.».

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие турында»

2019 ел, 7 сентябрь, 803 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 27 декабрь, 1207 нче; 2020 ел, 17 апрель, 304 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булган затларга.»;

6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Үзәк бүлеге ведомствоара сораулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып электрон формада айлык пособие билгеләү турында карар кабул итү өчен кирәкле түбәндәге мәгълүматларны ала:

балалар тууны дәүләт теркәвенә алу турында – Татарстан Республикасы территориясендә бала (балалар) тууны дәүләт теркәвенә алган очракта;

никахлашуны дәүләт теркәвенә алу турында – Татарстан Республикасы территориясендә никахлашуны дәүләт теркәвенә алган очракта;

халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт хезмәте органнары тарафыннан түләнә торган эшсезлек буенча пособие, стипендия, матди ярдәм алу һәм аның күләме турында;

Россия Федерациясе Пенсия фонды органнары тарафыннан түләнә торган пенсия һәм башка социаль түләүләр алу һәм аларның күләмнәре турында;

Россия Федерациясе Пенсия фонды органнары тарафыннан түләнә торган, эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан физик зат файдасына исәпләнгән түләүләр һәм башка бүләкләүләр суммасы турында;

Социаль иминият фонды органнары тарафыннан түләнә торган социаль түләүләр турында;

ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү яки ата-ана хокукларын чикләү турында;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмау турында.

Гариза бирүче үз инициативасы белән Үзәк бүлегенә бу пунктта күрсәтелгән мәгълүматлар бирелгән документларны тапшырырга хокуклы.»;

8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Айлык пособие билгеләүдән баш тарту өчен тапшырылган мәгълүматлар һәм (яки) документлар нигезендә ачыкланган аны алу хокукы булмау нигез булып тора.».

6. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына гражданнарның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмау турында мәгълүматлар алу өлешендә Федераль салым хезмәте белән ведомствоара электрон хезмәттәшлекне тормышка ашыруны тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин